ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

«1941 – 1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы чорында зыян күргән балаларга социаль ярдәм чаралары турында» федераль закон проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

1. Балачаклары 1941 – 1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы елларына туры килгән гражданнарга ярдәм итүгә юнәлдерелгән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы закон чыгару инициативасын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Э.С. Шәрәфиев тәкъдимен хупларга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты тәкъдимен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 113 статьясындагы 4 өлешенең 2 пункты нигезендә «1941 – 1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы чорында зыян күргән балаларга социаль ярдәм чаралары турында» федераль закон проектын эшләп бетерү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Э.С. Шәрәфиевка кире кайтарырга.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитетына 2022 елның 28 февраленә кадәр:

федераль закон проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Э.С. Шәрәфиев, шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт Советында «Единая Россия» фракциясе, «Россия Федерациясе Коммунистлар партиясе» фракциясе һәм башка депутат берләшмәләре белән берлектә эшләп бетерергә һәм аны Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертергә;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенә күрсәтелгән категориядәге гражданнарның статусын һәм аларга социаль ярдәм чараларын федераль дәрәҗәдә билгеләү турында тәкъдимне хуплау үтенече бәян ителгән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгатен әзерләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ю.З. Камалтыновка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2021 елның 17 декабре
№ 1248-VI ДС